ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ БАЙСАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423745, Иске Байсар авылы,
Мәктәп ур.,44 а йорт.
Тел 3-44-53
e-mail : bay.akt@yandex.ru

СОВЕТ СТАРОБАЙСАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

423745, с.Старое Байсарово,
ул.Школьная, дом 44а.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 12** **03.07.2020 ел**

**Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлегенең кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Иске Байсар авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районының Иске Байсар авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районының Иске Байсар авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 20.09.2007 елның 01 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. 1 нче кушымтаның 9 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

2. Актаныш муниципаль районының Иске Байсар авыл җирлеге Советының «Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә яңа редакциядә» 07.09.2017 елның 21 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а. Нигезләмәләнең 3.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсенең (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклары керми;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Иске Байсар авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Байсар авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык Р.М.Кадыйров